# Нәсыйхәт

җомга 30 март 2012 №14

**Рәхимле вә Шәфкатьле АЛЛАҺ исеме белән**
**Мамадыш мәдрәсәсенең айлык дини-иҗтимагый газетасы**


## Яңалыклар

**КОРЪӘН УКУ БӘЙГЕСЕ. Апрель ае башында мәдрәсәдә район Коръән уку бәйгесе узачак.** Бүгенге көндә авылларда ярышның беренче этабы бара. Әлеге бәйгедә мәхәлләләрдә беренчелекне яулаучылар катнашачак. Район күләмендә узачак бәйгенең йомгаклау этабына хакимият вәкилләре, ТР Диния нәзарәтеннән дә кунаклар көтелә.

**АЧЫК ДӘРЕС. Мамадыш мәдрәсәсендә Коръән тәфсире буенча ачык дәрес уздыру планлаштырыла.** Аңа башка дини уку йортларыннан укытучылар һәм методистлар килер дип көтелә. Мондый төрдәге ачык дәресләр үткәрү мөгаллимнәр арасында тәҗрибә алышуга җирлек тудырачак.

**ҖОМГА НАМАЗЫНДА. Мәдрәсә мөгаллимнәре тарафыннан авыл мәчетләрендә җомга намазлары укытыла.** Әлеге чараның максаты авылларда халыкның дин белән кызыксынуын арттыру, имамнар белән аралашу, мәдрәсәгә яңа шәкертләр җәлеп итү. Чираттагы җомга Олыяз авылы мәчетендә үткәрелде. Халык канәгать калды.

**ИГЪЛАН.** “Нәсыйхәт” **газетасы ислам тематикасына багышланган “Иң яхшы дини мәкалә” һәм “Иң яхшы дини шигырь” дип аталган конкурс игълан итә.** Җиңүчеләрне истәлекле бүләкләр көтә. Һәр катнашучының иҗади җимешләре безнең газетабызда бастырылачак. Мәкаләләр һәм шигырьләр 30 нчы апрельга кадәр кабул ителәләр. Аларны мәдрәсә электрон почтасына яки хат рәвешендә мәдрәсәгә җибәрүегез мөмкин. **Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, М. Җәлил ур. 8/28**

# “МОГҖИЗАЛАР КЫРЫ”

**Мамадыш мәдрәсәсе тарафыннан “Могҗизалар кыры” дип исемләнгән интеллектуаль уен үткәрелде.**

Анда мәдрәсә шәкертләре катнашты. Чараның максаты үзара бердәмлекне, кардәшлекне арттырып, алган белемнәрне тикшереп карау иде. Уен гадәттәгечә Коръән уку һәм дога кылу белән башланып китте. Чара дәвамында өч турдан торган дини викторина үткәрелде. Тамашачылар өчен дә дини сораулар әзерләнгән иде. Финалга Әлфия Зарипова, Фирая Мингалиева һәм Рафат хәзрәт үттеләр. Җиңгән уенчылар “Могҗизалар кыры” дип аталган уенда катнаштылар. Әлеге уенда җиңүне Рафат әфәнде яулады. Ул суперуенда да катнашып, абсолют җиңүче дип табылды, махсус бүләкләргә лаек булды.



**Мәдрәсә директоры Габдрахман хәзрәт уенны кызыклы һәм мавыктргыч алып барды. Фирая Мингалиева фотосы.**

Тамашачылар да, уенчылар да ошбу уенда бик актив һәм теләп катнаштылар. Иң тапкырлары һәм сорауларга дөрес итеп җавап биргәннәре истәлекле бүләкләргә ия булдылар. Уен вакытында кергән намазны җәмәгать белән, саф-саф тезелеп басып уку да нур өстенә нур булды. Уен уңаеннан табын да әзерләнгән иде. Барлык килгән кунаклар һәм тамашачылар казанда пешкән тәмле пылау белән сыйландылар. Алар чарадан бик канәгать калдылар һәм мондый очрашулар киләчәктә дә дәвамлы булсын диган теләк белдерделәр.

## ДӨНЬЯ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

**“Мусульмане” программасын эшләүче иҗат төркеме Татарстанның мактаулы исемнәренә лаек булды .**

“Мусульмане” программасын эшләүче иҗат төркеме, ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов Указы белән, Татарстанның мактаулы исемнәренә лаек булды. “Татаркино” оешмасыннан килгән хәбәргә караганда, алар бу бүләкләргә татар халкының рухи-әхлакый һәм мәдәни традицияләрен саклау һәм үстерүгә керткән күпьеллык хезмәте өчен лаек булган. Дәүләт бүләкләрен ТРның Россия Федерациясендәге Тулы вәкаләтле вәкиллегендә тапшырган вакытта Тулы вәкаләтле вәкил Равил Әхмәтшин, иҗат төркеменә башкарган хезмәтләре өчен рәхмәт белдереп, аларның Казан халыкара мөселман киносы фестивален оештыруга керткән өлешен билгеләп үтте. “Мусульмане” программасында 120дән артык тапшыруның Татарстанга багышланганын хәбәр итте.

**Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Татарстанда тарихи һәйкәлләрне яңадан торгызу өчен инвесторларның актив җәлеп ителәчәген белдерде.**

«Казан, Зөя, Болгар, Раифа — боларның барысы да безнең байлык. Туризмны үстерүдән тыш, тарихи һәйкәлләрне яңадан торгызуның тәрбияви әһәмияте дә зур дип уйлыйм. Балаларыбыз безнең үз тарихыбызга нинди мөнәсәбәттә торуыбызны күрәчәк. Тарихи һәйкәлләрне саклау һәм яңадан торгызуга акчалата ярдәм күрсәтергә теләүчеләрнең саны елдан-ел артыр дип өметләнәм»,–диде Рөстәм Миңнеханов.

**Дубайда Мөхәммәд Пәйгамбәрнең тормышына багышланган иң авыр китап күрсәтелде**

Дубайда Мөхәммәд Пәйгамбәрнең тормышына багышланган 1 тонна авырлыктагы китап тәкъдим ителде. Аның биеклеге–5 метр, киңлеге–4 метр. Мәдәни һәм дини кыйммәткә ия булган әлеге җыентык Гиннесның Рекордлар китабына кертелгән. Китапның максаты–теләге булган һәркемне ислам дине һәм мөселманнар тормышы белән якыннан таныштыру. Шәех Һәмдан инде 50 мең китапны бастырып чыгаруга заказ биргән. Алар төрле оешмаларга, шул исәптән, чит төбәкләрдәге җәмгыятьләргә җибәреләчәк.

**Чыганак: tatar-islam.com**

# БАЛАБЫЗ “БƏЛА” БУЛМАСЫН

**Элек-электəн бала тəрбиясе игътибарга лаеклы актуаль мəсьəлə булган. Бүгенге көн үзəгендə наркомания, эчкечелек, җинаятьчелек һəм башка социаль проблемалар булганда элеге тəрбия мəсьəлəсе иң əһəмиятлесе булып кала бирə.**

ГАБДРАХМАН ХƏБИБУЛЛИН,
**мəдрəсə директоры.**

Əлбəттə һəрбер ата-ана үз баласын тəрбияле итеп күрəсе килə, аның намуслы, миһербанлы, акыллы булуын тели, аны бəхетле итəсе килə. Ничек итеп тəрбия мəсьəлəсендə уңышка ирешергə? Балаларыбыз килəчəктə үзебезгə терəк һəм догачы, җəмгыятебезгə кирəкле шəхес булсыннар өчен нəрсə эшлəргə?
Дөньябыз зур прогресс кичергəн бу заманда балаларыбыз интеллектуаль яктан тиз өлгерəлəр. Алар телевизор, интернет һəм башка массакүлəм чараларында урын алган мəгълүмат тəэсирендə фикер йөртəлəр, нəтиҗə буларак аларның дөньяга карашы формалаша. Шушы шартларда балага нинди кыйммəтлəр турында аңлату, аларны тиешле дөрес юнəлешкə кертеп җибəрү аерата авыр мəсьəлəгə əверелə. Əмма, моңа да карамастан, баланың əхлакый формалашуында эти-əнинең роле əйтеп бетергесез. Дөньяда идеаль кеше юк дилəр, димəк ата-аналар да идеаль түгеллəр. Əмма алар, көчтəн килгəнчə барлык тəрбияви ысулларын кулланып, балаларын чын кеше итəргə бурычлылар. Шулай яшəргə кирəк: балаларыбыз бездəн ата-аналардан бөркелгəн мəхəббəтне, җылы мөгамəлəне, тынычлыкны, ярдəмне күреп үссеннəр. Əлбəттə, тəрбияви ысуллар биниһая күп. Кайберлəре аерата игътибарга лаек. Əгəр без бу ысулларны тиешле дəрəҗəдə куллана алсак, алар көттерми үзлəренең татлы җимешлəрен дə бирə башларлар.

**Балаларыбызны үзебез белəн мəчеткə алып барыйк.** Шулай итеп без аларда Аллаһ йөртына карата мəхəббəт тəрбияли алырбыз. Мəчеткə йөрергə гадəтлəнсəлəр, бозыклык кылына торган җирлəргə аяк та басмаслар. Мəчеттə алар яңа дуслар да табачак. Əлеге тəрбияви алым нəтиҗəсендə балалар гыйбадəткə хирыслыкларын арттырачак, яман гадəтлəрдəн арынып, Аллаһны



танырга өйрəнəчəклəр. Риваятьлардан күренгəнчə Пəйгамбəребез дə үзенең оныкларын мəчеткə иярттə торган булган. Хəтта бервакыт сəҗдə вакытында оныкларының берсе аның иңсəтенə менеп утырган. Оныгы төшкəч кенə, ул сəҗдəдəн торып, намазын тəмам кылган. Шулай итеп Пəйгамбəребез оныгын шатлыгыннан аерасы килмəгəн.
Мəчеттə намаз уку балаларны тəгəллеккə дə өйрəтə, чөнки Аллаһ тарафыннан намазны махсус вакытларда уку тиешле. Җəмəгать намазларында катнашып, тигез рəтлəргə басып сафсаф булып намаз башкаручылар балаларда кардəшлек хисен тəрбияли, алар олыларга карата шəфкатьле булырга өйрəнəлəр. Имамның Корьəн укуын тыңлап торып бала Корьəнне ярата башлый, аны укуда даимичелек кылып, Аллаһ сүзлəре белəн таныша. Бирəдə ул шулай ук тəһарəт алганда суны əрəм итмичə генə кулланырга өйрəнə. Килгəн-киткəн кешелəргə сəлам биреп, мөселманча исəнлəшү һəм саубуллашу əдəплəрен үзлəштерə. Андагы мөселманнар белəн аралашу балада үз-үзенə ышанучанлыкны арттыра, күңелендə ярдəмлəшү хислəре уяна, мəчеттə аны һəрвакыт көтеп һəм яратып торуларын тану аны яңадан мəчеткə алып килə. Шулай ук, мəчеткə йөрү аны һəрвакытта да Аллаһка догада булырга тиешлеген өйрəтə, беркайчан да кайгыга бирешмичə Аллаһның тəкъдиренə риза булырга кирəклеген тəрбияли. Менə ни өчен сəхəбəлəр дə мəчетлəргə үз балалары белəн килə торган булганнар. Берсүзсез, Пəйгамбəребез вакытында балалар өчен мəчет уртак мəрхəмəтлек, татулык йорты булган. Алар анда олылар тарафыннан булган шəфкатьлекне һəм мəхəббəтне тойганнар һəм шушы уңай йогынтыны кешелек дөньясына алып чыгып, бар яктан да үрнəк шəхеслəр булып өлгергəннəр. Безнең заманыбызда да шушындый үрнəк яшьлəр күбрəк булсын дисəк, балаларыбызны мəчетлəргə йөртик. Əлбəттə, бүгенге компьютер һəм интернет заманында балаларда мəчеткə карата мəхəббəт хисен уяту җиңел эшлəрдəн түгел. Шулай да, нарасыйларыбызны йомшаклык һəм хикмəт белəн кечкенə чактан ук əлеге күркəм гадəткə гадəтлəндерсəк тырышлыгыбыз нəтиҗə бирмичə калмас. Оныты ярамый: катылык һəм көч кулланып, без балаларыбызны Аллаһ йортына китерə алмаячакбыз. Бары тик шəхси үрнəгебез һəм җылы сүзлəребез генə бу авыр вазыйфаны нəтиҗəле итəчəк.

**Балаларыбызга Аллаһ һəм дин турында сөйлик.** Əлеге хикəялəр һəм риваятьлар бүгенге бозыклык таралган заманда балаларыбызга дөрес юлга күнегергə ярдəм итəр. Яши торган дөньябызда Аллаһы Раббыбызның нигъмəтлəре биниһая күп. Ай, кояш, еллгалар, таулар, болыннар... Балаларыбыз кечкенəдəн үк бу олы хакыйкатьне белергə һəм аңларга тиешлəр: боларны барысын да Аллаһ яраткан.

Бөек Раббыбызның барлыгын һəм берлеген тану аларга килəчəктə дə ярдəм итəчəк. Чөнки кечкенəдəн иман төшенчəлəре белəн таныш булмаган балалар үсеп җиткəч күбрəк депрессиягə һəм башка тискəре сыйфатларга дучар булалар. Ə иманлы бала исə, авыр минутларында да үзенең ярдəмчесе Аллаһ барлыгын аңлый һəм төрле проблемаларны җиңел кичерə, ул телəгəн əйберен хыялында гына йөртмичə, Аллаһтан сорап дога кылырга гадəтлəнə. Һəрберебезгə мəгълүм ки, безнең тирə-юнебездə бик күп матурлык яшеренеп ята. Бу матурлыкның серен чишеп, балаларыбызның сокланганнарын күзəткəнебез бар. Əлбəттə үзенең сокланулары белəн ул безнең белəн дə бик телəп уртаклаша. Менə шушы мизгеллəрдə балаларыбызның матурлык белəн сокклануларын Аллаһка карата шөкер кылырга, аны мактарга юнəлдерергə тиешбез. Бисмиллə əйтеп һəр эшне башларга гадəтлəндерү дə үз вакытында, ягъни кечкенəдəн үк булырга тиешле.

**(Дəвамы 3нче биттə.)**

# БАЛАБЫЗ “БӘЛА” БУЛМАСЫН

**(Ахыры. Башы 2нче биттә).**
Безнең бәләкәчебез Аллаһының бик мәрхәмәтле, бик гадел, бик ярдәмчел, бик кодрәтле икәнлеген аңларга тиеш. Әлбәттә бу аңлатуларны баланың яшь категориясен күздә тотып башкарырга кирәк. Кыскасы бала өчен Аллаһ һәм дин турында ишетү бик тә рәхәт булырга тиеш. Ул сезнең чираттагы сөйләвегезне түземсезлек белән көтеп торсын. Бала үскән саен исламда тиешле булган гамәлләр турында сөйләүне һәм аңлатуны да гадәткә кертергә кирәк. Әмма әлеге аңлатуларны баланы куркытып түгел, Аллаһының газаплары турында сөйләп түгел, бәлки йомшаклык белән һәм хикмәт белән башкарылуы көн кебек ачык. Онытмаска кирәк, башта сабыйларыбызда Аллаһка карата мәхәббәт тәрбияләргә кирәк, аннан соң гына тора бара, әкреннәп-әкреннәп гыйбадәт турында да сүз алып бара башларга мөмкин.

**Балага хикмәт белән, аерата үтемле формада кыямәт көне турында да аңлатыгыз.** Һәрбер гаиләдә авыру, үлем китем ише тетрәндергеч вакыйгалар булмый тормый. Моны әлбәттә бала да күрә. Күп ата-аналарда балаларны әлеге вакыйгалардан ерак тоту фикере киң таралган. Әмма Пәйгамбәребез, киресенчә, балаларны шушы вакытларда җәлеп итеп, аларга дини мәсьәләләр турында сөйләүне хуплый торган булган. Кечкенә яшьтәге бала гадәттә үлемнән курыкмый. Ни өчен дигәндә, әле ул үлемнең нәрсә икәнен аңламый. Әмма инде 2-3 яшьтә бала үлем дигән сүзне үз лексиконында куллана башлый. Мисал өчен уенчык пистолетның курогына басып “Син үлдең”, - ди. Ә менә инде 5-6 яшь тулган дәвердә бала кешенең авыруы белән үлем арасындагы элемтәне аңлый башлый. Шуңа күрә мондый вакытларда баланың сорауларына ялганламыйча, ачык һәм дөрес итеп җавап бирү кирәк. Мисал өчен баланың: “Кешеләр үлгәннән соң кая китә?”,- дигән соравына үлгәннән соң яңадан терелү барлыгы турында аңлатырга ярый. Әмма баланы үлем белән куркытырга һич ярамый. Гомумән алганда, үлем темасы дин темасына якын. Сөйләшүләрдән соң бала шуны аңларга тиеш: Аллаһы Тәгалә кешеләрнең җанын алучы явыз зат түгел, бәлки киресенчә ул кешеләргә үлгәннән соң тагын да рәхәтрәк тормыш бирүче.

**Балаларыгызны Ислам бәйрәмнәре белән таныштырыгыз һәм әлеге бәйрәмнәрне гаиләгез, балаларыгыз белән истә калырлык итеп үткәрергә тырышыгыз.**
Дөрестән дә Пәйгамбәребез дә дине бәйрәмнәргә бик тә игътибар иткән. Аларны кызыклы итеп, уеннар, шатлык белән үткәрә торган булган. Пәйгамбәребез заманында әлеге бәйрәм көннәрне олысы, кечесе рәхәтләнеп ял иткәннәр. Без дә шушы бәйрәм рухын балаларыбызга сеңдерергә бурычлы. Бүген безнең балаларыбыз яңа ел, яз бәйрәмнәрен көтеп алалар. Шушы ук мисалда алар Ислам бәйрәмнәрен дә түземсезлек белән көтеп алырга тиешләр. Аның өчен әлбәттә аларда кечкенә чактан ук әлеге бәйрәмнәргә карата мәхәббәт уятырга кирәк, бу бәйрәмнәрне истә калырлык итеп, бүләкләр, төрле уеннар, күчтәнәчләр һәм башка күңелле ысуллар белән алып барырга гадәтләнергә кирәк. Шушы бәйрәм чараларыннан бала зур әхлакый дәресләр ала: ул туганнарның хәлләрен белергә өйрәнә, үз киемен чиста тоту гадәтен үзләштерә, баланың күңелендә шушы чисталыкка өндәгән Пәйгамбәребезгә мәхәббәт хисе урнаша, йөрәгендә кардәшлек тойгылары уяна, бәйрәмгә килгән йөзәрләгән мөселманнарны күреп, Ислам динендәге зур бердәмлек күренешләренә тап булып, үз дине белән горурлык хисләрен тоя башлый. Рамазан бәйрәменә килгәндә күп ата-аналар үз балаларына ураза тоттырмыйлар, җәллиләр. Балалары бәлагатькә ирешкән булсалар да бераз үссен әле, бик кечкенә бит дип, ураза тотудан ераклаштыралар. Шул ук вакытта яше бәлагатькә ирешеп тә ураза тотмау зур гөнаһ икәнен онытып җибәрәләр. Шулай итеп үз балаларын Аллаһ газабына дучар иттерәләр. Югыйсә, Рамазан мәдрәсәсенең безгә биргән дәресләре аерата игътибарга лаек. Бу ай кешеләрдә юмартлык, ярдәмчеллек, мәрхәмәтлелек хисләрен тәрбияли. Сабырлыкка, гыйбадәткә, ятим-мескеннәрнең хәлләрен белергә өйрәтә.

**Балаларыгызга Ислам турында шигырьләр, хикәяләр укыгыз. Аларны яттан укырга гадәтләндерегез. Дингә багышланган җырлар һәм мөнәҗәтләр өйрәтегез.**
Сер түгел бала табигате көйле һәм рифмалы шигырь, хикәяләрне бик ярата. Хәтта тыңлаган әсәрләрнең барысын да аңлап җиткермәсә дә, бала белән әлеге юнәлештә эш алып бару файдалы нәтиҗәләрне бирә. Бала ошбу ысул аша Аллаһ һәм аның илчесе турында ишетә, укуын яхшырта, тыңларга һәм оялмыйча яттан сөйләргә өйрәнә. Бүгенге көндә кибет киштәләрендә ислам тематикасына кагылышлы бик күп файдалы мультфильмнар, кинолар, төрле-төрле уеннар бихисап. Бу мөмкинлекләрне барысын да кулланырга кирәк.

**Балаларыгызны үзегезнең шәхси үрнәгегез белән тәрбияләгез.**
Гаиләгездә һәрвакыт яхшы мөгамәлә, ярдәмчеллек, мәрхәмәтлелек, гаделлек хөкем сөрсен. Гамәл-гыйбадәтне иң беренче ата-ана үзе үз баласына үрнәк булган дәрәҗәдә башкарырга бурычлы. Балаларын тәрбия кылганда түбәндәге ысулларны җиренә җиткереп кулланырга тиешле: 1. Баланың яхшы эшләрен бәяләргә онытмагыз. 2. Нарасыйларыгызга каты бәрелмәгез, хикмәтле сүзләр белән һәм йомшаклык белән генә эш итегез. 3. Үз балагызга карата игътибарлы булыгыз. 4. Тәрбия эшләрендә ихласлы булыгыз һәм Аллаһы Раббыбыздан хәерле нәтиҗәләр сорагыз.

## Сез беләсезме?

**Җәннәт әхелләренең күбесе фәкыйрьләр, җәһәннәм әхелләренең күбесен хатыннар тәшкил итәр.**

Пәйгамбәребез әйтте: “Җәннәттә мин күбрәк фәкыйрьләрне күрдем, җәһәннәмгә карагач анда күпчелеге хатыннар иде”,–диде. *(Фатх-аль-Бари 6/318)*

**Кеше үлгәч аңа иртә-кич җәннәттәге яки җәһәннәмдәге урыны күрсәтеләчәк.**
Пәйгамбәребез әйтте: “Кеше үлгәч аңа иртә-кич җәннәттәге яки җәһәннәмдәге урыны күрсәтеләчәк. Әгәрдә кеше җәннәткә лаек булса, үлгәннән соң аңар җәннәттәге урыны күрсәтелер һәм “Менә синең киләчәктәге урының”,–дип әйтелер. Әгәр дә кеше җәһәннәмгә лаек булса, үлгәннән соң аңар җәһәннәмдәге урыны күрсәтелер һәм “Менә синең киләчәктәге урының”,-дип әйтелер. *(шарх Сахих Мөслим (17/300)*

**Җәннәт ишекләренең күгәннәренең арасы Мәккә шәһәре белән Басра шәһәре арасы кебек булыр.**
Пәйгамбәребез әйтте: “Аллаһы Тәгалә белән ант итәм, җәннәт ишекләренең күгәннәренең арасы Мәккә шәһәре белән Басра шәһәре арасы кебек”.*(Аль-бидайа ва-н-нихайа 2/221)*

**Иң беренче җәннәткә керәчәк кеше безнең пәйгамбәребез булачак.**
Пәйгамбәребез әйтте: “Мин җәннәт ишекләрен кагучы иң беренче кеше булырмын” *(Мөслим)*

**Житмеш мең кеше җәннәткә хисапсыз керер.**
Пәйгамбәребез әйтте: “Минем өммәтемнән житмеш мең кеше җәннәткә хисапсыз керер. Аларның йөзләре тулган ай кебек, йөрәкләре барысының да бер төрле булыр. Мин Раббымнан бу кешеләрнең санын арттыруын сорадым, ул миңа һәр меңе саен тагын житмеш мең бирде. *(Әхмәд)*

**Җәннәттә иң дәрәҗәле урын “вәсилә” дип аталыр.**
Пәйгамбәребез әйтте: “Җәннәттә иң дәрәҗәле урын “вәсилә” дип аталыр. Әлеге урынны догаларыгызда минем өчен сорагыз.”

## Викторина

**Кадерле укучыларыбыз, сезгә Ислам тематикасына кагылган викторина сорауларын тәкъдим итәбез. Иң беренче дөрес итеп җавап бирүчене истәлекле бүләк көтә.**

1) Пәйгәмбәребез җәннәттә нинди сәхәбәнең аяк тавышларын ишеткән?
2) Пәйгамбәребез Мәдинә шәһәренә күчкәннән соң иң беренче төзелгән мәчет ничек аталган?
3) Аллаһ Муса пәйгамбәргә нинди 9 могҗиза бирде?
4) Ислам динен беренче кабул иткән бала?
5) Аллаһка иң беренче сәҗдә кылган фәрештәнең исеме ничек?
6) Ибраһим галәйһиссәләм кайда туган?
7) Кайда һәм ничәнче елда Пәйгамбәребез вафат булды? Иң ахыргы тулысынча иңгән сүрәне әйтегез?
8) Мәдинә шәһәре хиҗрәткә кадәр ничек аталган?
9) Нинди айда Мәккә шәһәре потларга табынудан азат ителде?
10) Ничә мәртәбә пәйгамбәребез Коръәндә үз исеме белән зекер ителгән?
11) Нинди ике пәйгамбәр Коръәндә ике генә мәртәбә зекер ителгән?
12) Коръәндә ничә сүрә пәйгамбәрләр исемен йөртә?
13) Ничәнче елда мөселманнарга зәкәт түләү фарыз булды?
14) Кәгъбәтулланың һәр дүрт почмагын исемләп атагыз?
15) Нинди сәхәбә иң күп хәдисләр риваять кылган? Ул риваять кылган хәдисләрнең санын зекер итегез?
16) Сөләйман пәйгамбәрнең нинди ике хайван белән сөйләшкәне Коръәндә зекер ителгән?
17) Хиҗри ел берәмлеге кайчан һәм кем тарафыннан кертелгән?
18) Коръәннең нинди һәм ничәнче аятендә шайтан җен токымыннан икәнлеге әйтелгән?
19) Минада өч багана бар? Алар ничек аталалар?
20) Риваятьләр буенча сәхәбәләр бер-берсе белән очрашканда һәм саубуллашканда нинди сүрә укый торган булганнар?

## Белдерүләр

**Мәдрәсә базасында атнаның һәр ялында балалар өчен әхлак дәресләре алып барыла. Укуларга рәхим итегез.*

**Мәдрәсә бинасында ислам атрибутикасы кибете эшли. (Коръән китаплары, шамаилләр, тмин майлары, дисбеләр, дини китаплар, түбәтәйләр һ.б.)*

**Балага исем кушу, никах уку һәм башка дини мәрәсимнәрне үткәрү. Мамадыш мәдрәсәсе, М. Җәлил ур 8/28), тел: 89172802391*

**Намаз, Коръән укырга, дин гыйлемен өйрәнергә теләгән һәр кешене мәдрәсәдә оештырылган кичке уку курсларына чакырабыз.*

**Мәдрәсә базасында Ислам диненә караган сорауларга җавап бирү хезмәте.*

**Белешмәләр өчен телефон: 89172802391**

## Укырга чакырабыз

# Мамадыш мәдрәсәсенә рәхим итегез!

Татарстан Җөмһүрияте Мөселманнары Диния Нәзарәте каршындагы Мамадыш мәдрәсәсе 2012-2013 уку елына шәкертләр туплый.

Белгечләр әзерләү көндезге һәм кичке уку рәвешендә алып барыла.

Көндезге бүлеккә яше 14тән дә ким булмаган егетләр кабул ителә. Шәкертләр мәдрәсә тулай торагында яшәү урыны һәм көнenә өч тапкыр ашау-эчү белән тәэмин ителәләр. Уку вакыты – өч ел. Урта белем алу икенче санлы лицей базасында алып барыла. Мәдрәсәне тәмамлаганнан соң шәкертләргә квалификация комиссиясе карары нигезендә тиешле белгечлек алу турында диплом бирелә.

Укырга керү өчен кабул итү комиссиясенә түбәндәге документларны тапшырырга кирәк:

**1) Гариза**
**2) Белем турында таныклык**
**3) 086-формасында сәламәтлек турында белешмә**
**4) Паспорт (копия)**
**5) 3х4 үлчәмендә 4 фотосүрәт**
**6) №26 формасында индивидуаль медицина картасы**

**Документлар 30 августка кадәр кабул ителә.**

*Намаз укырга өйрәнергә һәм дин белемен үзләштерергә теләүчеләр өчен мәдрәсәдә кичке уку бүлеге һәм читтән торып уку бүлеге эшли. Бу бүлекләргә хатын-кызлар һәм ир-егетләр кабул ителә. Яшь чиге куелмаган.*

*Безнең адрес: Татарстан Республикасы, Мамадыш шәһәре, М. Җәлил урамы 8/28,*

**Телефоннар: 3-19-17, 89172802391**

## Сорау-җавап

**•Минем белән берничә тапкыр шундый хәл булды: төнлә уянып киткәч, күзләремне ача, сулый алам, әмма хәрәкәтләнә алмыйм. Бармаклар катып калган, иреннәр дә селкенми. Бу вакытта кемдер мине күзәткән кебек сизәм. Мондый хәл бер минутка кадәр дәвам итә. Әлеге күренешкә берәр аңлатма бармы? АРСЕН**

–Йокы ул–кече үлем, ял итү һәм безнең акылыбызга буйсынмаган көчләр белән элемтә каналы. Бервакыт Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с. г. в.) иртән йокыдан торгач, сәхәбәләргә: «Чынлыкта, Раббыбыз Үзе теләгән вакытта сезнең җаннарыгызны алды һәм аларны теләгән вакытта кайтарып бирде»; «Рәхмәт безләрне үтергәннән соң яңадан терелткән Аллаһыга (Ул йокы вакытында җаннарыбызны алды һәм тормышны дәвам итү өчен аны кире кайтарды)»,-диде.

Сезнең йоклаганда чыккан җаныгыз тәнегезгә акрынлап кире кайтканы өчен уянган чагында төш күргәндә шундый хәлләр килеп чыга.

**•Имам артыннан намазны ничек укырга?**

–Җәмәгать намазы дәресләрендә имам Коръән укыганда эчтән булсын яки тавыш белән, аның артыннан кабатларга ярамый, диелгән. Бу җәмәгать белән укыганда 3, 4 рәкәгать фарыз намазларында, 1, 2 рәкәгать зухр һәм гаср намазларында "Фатиха"ны укымаска дигәнне аңлатамы?

–Әйе, Хәнәфит мәзһәбе буенча, җәмәгать намазында имам тавыш белән яки үзеннән генә укыса да, аның артыннан кабатларга кирәкми. Чөнки аның намазы – артыннан басып торучыларның да намазы булып санала.

**Җаваплар umma.ru дан алынды**

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең Бөек исемнәре булганга күрә, аны саклап тотуыгыз сорала**

**Баш мөхәррир: Хәбибуллин А.М. Мөхәррир урынбасары: Хәбибуллина Э.Р.**
**Дизайн һәм верстка: Мингалиева Ф.Н. Җаваплы сәркатип: Спиридонова А.С.**
**Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы,8/28. mamadysh-medrese@mail.ru. Газета "Татмедиа" ААҖнең Мамадыш муниципаль районы"Нократ" мәгълүмат-матбугат филиалында басылды. Тираж татар телендә 100 данә.**